| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НОРЛАТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«31 « январь 2022 ел** **№4**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Җирләү һәм җирләү эше турында»1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары нигезендә, Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә Яшел Үзән муниципаль районы Норлат авыл җирлегендә 6 964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. 2021 елның 1 февраленнән 3нче номерлы "Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» гы Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты карарын 2022 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru" Интернет " мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә» урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 нчы йорт (җирлек администрациясе бинасы), Норлат авылы, М.Фәйзуллин урамы, 17 нче йорт (ЦКС «Заволжье» бинасы) адреслары буенча Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Норлат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Норлат**
**авыл җирлеге башлыгы** **И.М.Саттаров**

Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты 31 январь 2022ел №4 карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлегендә җирләү гарантияле исемлеге буенча 2022 ел 1 февральдән башлап хезмәт күрсәтү бәясе

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3795,41 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка ташу | 1081,18 |
| 4. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2088,09 |
| **Барлыгы** | **6964,68** |

Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты 31 январь 2022ел №4 карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлегендә җирләү гарантияле исемлеге буенча 2022 ел 1 февральдән башлап хезмәт күрсәтү бәясе

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. гәүдәне төрү | 670,55 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3124,86 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратта ташу | 1081,18 |
| 5. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү ) | 2088,09 |
| Барлыгы | **6964,68** |